СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 159 от 08.11.2022
на № _________от ______________

# К А Р А Р

Саба муниципаль районы Советының 2012 елның 7 сентябрендәге 136 номерлы карары белән расланган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе турында» 2012 елның 7 сентябрендәге 136 номерлы карары белән расланган, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Тәртипнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Тәртип нигезендә җир кишәрлекләрен бирү турындагы карарлар түбәндәге гражданнарга карата кабул ителә:

- Саба муниципаль районы территориясендә биш ел даими яшәүчеләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торалар, күпбалалы гаиләгә бушлай җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү датасына өч һәм аннан күбрәк балага, шул исәптән үги улларга, үги кызларга, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алучылар һәм унсигез яше тулмаган тәрбиягә алынган балаларга (опека һәм попечительлек срогы чикләнмәгән яки балигъ булганчыга кадәр башкарыла) ия булучылар.

2) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Закон) үз көченә кергән көнгә, баланың (балалар) балигълык яшенә җитүенә бәйле рәвештә җир кишәрлеге бирү (тапшыру) хокукын югалткан Саба муниципаль районы территориясендә биш ел дәвамында даими яшәүчеләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торалар, өч һәм аннан күбрәк балага, шул исәптән үги улларга, үги кызларга, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алучылар һәм 2011 елның 17 июненә

унсигез яше тулмаган тәрбиягә алынган балаларга (опека һәм попечительлек срогы чикләнмәгән яки балигъ булганчыга кадәр башкарыла) ия булучылар.

3) закон үз көченә кергән көннән өч ел эчендә җир кишәрлеге бирү (тапшыру) хокукын югалткан Саба муниципаль районы территориясендә биш ел дәвамында даими яшәүчеләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торалар,  өч һәм аннан күбрәк балага, шул исәптән үги улларга, үги кызларга, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алучылар һәм 2011 елның 17 июненә унсигез яше тулмаган тәрбиягә алынган балаларга (опека һәм попечительлек срогы чикләнмәгән яки балигъ булганчыга кадәр башкарыла) ия булучылар.

**1.2.** Тәртипнең 3 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.3.** Тәртипнең 3.1 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.4.** түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт өстәргә:

«3.3. Әгәр дә  ата-ананың берсе яки бердәнбер ата-ана  Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел яшәсә,.өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә даими яшәү турында әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган тәртипкә туры килә дип санала»;

**1.5.** Тәртипнең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Гаризаның электрон формасы бирелгәннән соң утыз көн эчендә Мөрәҗәгать итүче турыдан-туры вәкаләтле органга тапшыра:

1) мөрәҗәгать итүченең паспорты;

2) икенче ата-ана паспорты (әгәр ата-ана никахта торса йә никахта тормаса, тик бергә яшәгән очракта);

3) балалар туу турында таныклык, шулай ук ундүрт яшькә җиткән балалар паспорты;

4) баланы уллыкка алуны билгеләү турында суд карары (баланың туу турындагы таныклыкта уллыкка алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан тыш);

5) опекун яисә попечитель билгеләү турында опека һәм попечительлек органы акты (опека яисә попечительлек билгеләнгән очракта);

6) опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (шартнамә буенча опека яисә попечительлек гамәлгә ашырылган очракта).

7) никахлашу турында таныклык (ата-ана никахта торган очракта);

8) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак бинада мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ;

9) җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә мөрәҗәгать итүченең даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүче паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы Саба муниципаль

районы территориясендә аның яшәү урыны буенча теркәлүе турында тамга булмаган очракта).

Әлеге пунктның 8 пунктчасында күрсәтелгән документ, әгәр мөрәҗәгать итүче аны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.»;

**1.6.** Тәртипнең 21 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.7.** Тәртипнең 23 пунктындагы икенче абзацында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.8.** Тәртипнең 32 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның өч тапкыр җир кишәрлеген сайлаудан баш тартуы, яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына гражданнарның өч тапкыр килмәве, яисә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәү очракларының гомуми саны өчкә тигез булганда, мөрәҗәгать итүче вәкаләтле орган карары белән исемлектән төшереп калдырыла. ;». Гаризага «Мөрәҗәгать итүчене исемлеклардән төшереп калдыру турында карар кабул ителде» статусы бирелә;

**1.9.** Тәртипнең 1 кушымтасының «Җир кишәрлеген максатчан куллану кодлары» таблицасында 2 пунктны төшереп калдырырга.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов